

Шәриф Камал (чын исеме Шәриф Камалетдин улы Байгильдеев) - татар әдәбияты классигы, язучы, драматург һәм журналист 1884 елнын 27 февралендә Рузаевка районы Татар Пешләсендә туа. Татар әдәбиятында новелла жанрына нигез салучыларнын берсе. Совет чоры ижаты белән социалистик реализм юнәлешенә зур олеш керткән. ТАССР Атказанган сәнгать эшлеклесе, Ленин ордены иясе (1940 ел).
1950 елны Шәриф Камалнын Островский урамындагы квартирасында рәсми рәвештә әдипнен фатир-музее ачыла. 1959 елдан Шәриф Камал яшәгән йорт республика кvләмендәге мәдәни мирас объекты булып санала. 1961 елдан язучынын каберлеге дә республика кvләмендәге мәдәни мирас объекты буларак саклауга куелган.



1953 елдан Казаннын элеккеге Иске Вахитов урамы Шәриф Камал исемен йортә. Шулай ук язучынын исеме Яшел Үзән шәһәрендәгеурамга бирелгән. 2020 елда Татарстан Мәдәният министрлыгы, Татарстан Милли музее һәм Татар китабы йорты Шәриф Камал исемендәге әдәби премия булдырган. Болар барысы да Татарстанда.
Мордовиядә Шәриф Камалнын Рузаевка районы Татар Пешлә авылындагы туган йорты урынында мемориаль такта урнаштырылган. Юбилей конендә чәчәкләр бәйләме салынды. Шул урам анын исемен йортә. Туган  авылында анын исемен йорткән Татар Пешлә мәктәп музеенда якташ язучыбызга багышланган экспозиция янартылган. Әйтеп китәргә кирәк, vткән елда мәктәпкә капиталь ремонт ясалды. Мордовия мәктәпләрендә якташ язучыларыбызга атап стендлар эшли. Татар Пешлә урта мәктәбендә ел саен язучынын туган конен билгеләп vтәләр (Мордовия мәктәпләрендә дә), юбилей даталарда регионара чаралар vтә.



Менә якташ язучыбыз, татар әдәбияты классигы Шәриф Камалнын туган конендә, 27

февральдә, Татар Пешлә мәктәбенә тагы кунаклар жыелды. Алар арасында Шәриф Камалнын олы абыйсы Гыймадинен оныкчыгы - Нафис Анвар улыБайгильдеев, «Наследие Булгар» Казан продюсерлар компаниясе директоры; Рузаевка районы хезмәткәрләре; Татар Пешлә авылы житәкчесе Ринат Дявлюк улы Шабаев (чыгышы эчтәлекле булды); авыл Советы депутатлары; Саранскτагы Рухи-мәдәни vзәге вәкилләре;  Кочкурово районы Татар Умысы авылы имамы Рафаэль-хазрат Манюров; А.С.Пушкин исемендәгеМордовия китапханә хезмәткәрләре, дин әхелләре һәм кин жәмәгатьчелек вәкилләре катнаштылар.
Юбилей кичә бик матур һәм эчтәлекле оештырылган иде. Язучынын сәхнәләштерелгән биографиясе профессиональ дәрәжәдә куелды, Шәриф Камал турында истәлекләр белән уртаклаштылар, Наталья Нарваткина башкаруында скрипка уйнады, “Татар Пешлә авылы” һәм “Кайтам туган авылыма” жырларын Зульфия Гундина ихластан башкарды, «Матур кызлар», «Сандугачлар» ансамбльләре татар жырларын янгыраттылар, «Алма С» бию коллективы матур биеде, Татар Пешлә мәктәбе укучылары сәнгатьле иттереп шигырьләр, язучы әсәрләреннән озекләр укыдылар.

Мәктәп музеенда да туган Татар Пешлә авылы, халкы, аерым алганда Шәриф Камал турында эчтәлекле экскурсия vтте.
Истәлекле юбилей конне Шәриф Камал мирасын саклауда хезмәттәшлек очен Рузаевка главасы Рәхмәте Нафис Анвар улы Байгельдеевка тапшырылды.
Бу бәйрәмне Татар Пешлә мәктәбе директоры Флора Ахметжан кызы Шамонова оештырды.

**Наилә НАСЫРОВА**